СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

12.09.2019 — с. Набережные Моркваши — 78-337

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п., Яр буе МоркВашы авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү буенча бердәм инициатива күрсәтергә:

"2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл җирлеге кешесеннән 500 сум үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алдагы эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:
- Яр буе Морквашы, Лесные Моркваши, Покровка авылларында юлларны ремонтлау;
- Никольский бистәсендә чишмәләрне төзекләндерү;
- Покровка авылында һәм Пустые Моркваши бистәсендә балалар мәйданчыгына инвентарь сатып алу:

**«ӘЙЕ»** **«ЮК».**

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

**Совет Рәисе ,**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Яр буе Морквашы авыл җирлеге**
**Башлыгы** ____________**И.Х.Гаязов**